КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 20 декабрь г.Казань № 1181

2018-2020 елларга Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авырлык үлчәү контролен үстерү стратегиясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2018-2020 елларга Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авырлык үлчәү контролен үстерү стратегиясен (алга таба – Стратегия) расларга.
2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына Стратегиядә каралган чараларны үтәүне тәэмин итәргә.
3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына бүлеп бирелгән полосаларда авырлык үлчәү контроле мәйданнарын һәм пунктларын урнаштыруны килештергәндә булышлык күрсәтергә тәкъдим итәргә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин